# Татар телендә урта гомуми белем бирү мәктәбенең 11 нче сыйныфында укучы татар балалары өчен татар теленнән үткәрелә торган район олимпиадасы биремнәре (2015/2016 нчы уку елы)

**Үткәрү вакыты - 3 сәгать** **Максималь балл - 64**

## I. Тестлардан берәр дөрес җавапны билгеләгез.

1. Сүз басымы семантик вазыйфа башкарган вариантны билгеләгез. **(2 балл)**
   а) быелгыдай;
   ә) вакланма;
   б) утырмаска;
   в) кулъяулык.

2. Авазның төп үзенчәлекләре буенча сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   Тел алды тартыгы, йомык, саңгырау; түбән күтәрелешле, алгы рәт сузыгы, иренләшмәгән; ирен-ирен тартыгы, сонор.
   а) сан;
   ә) фән;
   б) тәм;
   в) шәл.

3. **Этнонимика** терминына дөрес бирелгән аңлатманы билгеләгез. **(2 балл)**
   а) тел белеменең кеше исемнәрен өйрәнә торган бүлеге;
   ә) тел белеменең төрле кушаматларны өйрәнә торган бүлеге;
   б) тел белеменең төрле кабилә, халык исемнәрен өйрәнә торган бүлеге;
   в) тел белеменең төрле торак пунктларның исемнәрен өйрәнә торган бүлеге.

4. ***Аңлавыгызча*** сүзенең мәгънәле кисәкләргә дөрес бүленгән вариантын билгеләгез. **(2 балл)**
   а) аң-лау(в)-ыгыз-ча;
   ә) аңла-выгыз-ча;
   б) аң-ла-вы-гыз-ча;
   в) аң-ла-в(у)-ыгыз-ча.

Сүзнең үзендә мәгънәле кисәкләрнең шартлы билгеләрен куегыз. **(2 балл)**

***аңлавыгызча***

5. ***Кисәк, капыл, дәррәу*** сүзләре белән бер синонимик рәткә керә торган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) һәрчак;
   ә) кинәт;
   б) тиз генә;
   в) аерым.

6. *Нуриасма башын бераз күтәрде дә карашын, Ык аръягы өстеннән йөгертеп, еракка, зәңгәрсу өрфия артында күкләргә ашып торучы Чия тавына юнәлтте.*

(Ф. Садриев) җөмләсендә ясалма нигезле ничә сүз барын билгеләгез һәм ул сүзләрнең астына сызыгыз. **(2 балл)**

а) 3;
ә) 4;
б) 5;
в) 6.

7. ***Ташла*** *инде, зинһар, барысын да әйттермә* (Ш. Камал) җөмләсендәге билгеләнгән сүзнең кайсы сүз төркеменә керүен күрсәтегез. **(2 балл)**

а) кисәкчә;
ә) ымлык;
б) боерык фигыль;
в) эндәш сүз.

8. Бугаз тартыгы (ларингаль тартык) кергән сүзне билгеләгез. **(2 балл)**

а) мохит;
ә) мөһер;
б) тәэсир;
в) сәнгать.

9. Җөмләдә ничә компонент булуы, аларның үзара ничек бәйләнүе һәм җөмләнең төре билгеләнгән җавапны күрсәтегез. **(2 балл)**

*Су буйларын яңгыратып,*
*Сызгырдым – борылмадың* (Ә. Атнабаев)

а) ике, санау интонациясе ярдәмендә бәйләнгәннәр, бу – теркәгечсез тезмә кушма җөмлә;
ә) бер, бу – гади җөмлә;
б) ике, аныклау интонациясе ярдәмендә бәйләнгәннәр, бу – иярченле кушма җөмлә;
в) ике, каршы кую интонациясе ярдәмендә бәйләнгәннәр, бу – теркәгечсез тезмә кушма җөмлә.

10. Составында исемләшкән сыйфат булган җөмләне билгеләгез. **(2 балл)**

а) Әүвәлге заманда булган ди бик ялкау ике кеше (Әкияттән).
ә) Гөрләп үсәбез, без – бәхетлеләр (Ә. Ерикәй).
б) Җемелди көз кояшында уттай яфрак һаман да (Ш. Маннур).
в) Үстердек кызыл гөлләр, сокланып үпте җилләр (З. Мансур).

11. *Ә күктәге кояш –*
*ерак көндә*
*өй янында үскән көнбагыш* (К. Мостафин) җөмләсендәге **кояш** һәм **көнбагыш** сүзләре арасындагы бәйләнешне һәм мөнәсәбәтне билгеләгез. **(2 балл)**

а) ияртүле бәйләнеш, хәбәрлекле мөнәсәбәт;
ә) ияртүле бәйләнеш, ачыклаулы мөнәсәбәт;
б) тезүле бәйләнеш, тиңдәшлек мөнәсәбәте;
в) ияртүле бәйләнеш, аныклаулы мөнәсәбәт.

12. *Җәрәхәттән каннар саркыса да,*
*Мин йөгәнли алам хисемне* (Ф. Тарханова) җөмләсендәге өтернең куелышын дөрес аңлаткан вариантны билгеләгез. **(2 балл)**

а) аерымланган кире хәлдән соң куелган;
ә) үзе бәйләнгән сүздән ераклашкан синтетик иярчен кире җөмлә белән баш җөмлә арасына куелган;

б) өтер тиңдәш кисәкләр арасына куелган;

в) *да* тезүче теркәгече ярдәмендә бәйләнгән тезмә кушма җөмлә компонентлары арасына куелган.

13.Җөмләнең төрен билгеләгез. **(2 балл)**

*Көлеп язлар килсә, карлар эрер иде,*
*Гөлләр үсәр иде кар яткан җирдә* (К. Булатова)

а) катнаш кушма җөмлә;
ә) тиңдәш иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә;
б) тиңдәш түгел иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә;
в) берничә төр иярүле күп иярченле катлаулы кушма җөмлә.

14. Мәгънәдәш сүзләрне бер-берсенә теркәү юлы белән ясалган парлы сүзләр рәтен билгеләгез. **(2 балл)**

а) бала-чага, күрше-күлән, бүләк-санак;
ә) анда-монда, чиле-пешле, барлы-юклы;
б) уй-фикер, аң-белем, уен-көлке;
в) елдан-ел, кайта-килә, башма-баш.

15. Омонимнарның бер төре булган омоформаларны билгеләгез. Русчага тәрҗемә итегез. **(4 балл)**

а) бал – бал; ( )
ә) күн – күн; ( )
б) аксакал – ак сакал; ( )
в) ял – ял. ( )

16. Бирелгән сүзтезмәләрнең ничәсе ирекле, ничәсе тотрыклы? **(2 балл)**

*Җырга әйләнү, тузга язмаган, кылычтай үткен, санга сукмау, сөт чүлмәге, агач атка атландыру, чиләк белән су ташу, йокы чүлмәге, киләчәк өчен тырышу, мичкә-мичкә бал, күз бәйләнү.*

а) 5,6;
ә) 7,4;
б) 4,7;
в) 6,5.

17. Бәйләгеч сүз төркемнәренә кергән сүзләргә хас булган билгеләр рәтен күрсәтегез. **(2 балл)**

а) мөстәкыйль кулланылмыйлар, сүз ясалышында катнашмыйлар, төрләнмиләр, синтаксик функцияләре юк;

ә) мөстәкыйль кулланылалар, сүз ясалышында катнашмыйлар, төрләнәләр, җөмлә кисәге булалар;

б) мөстәкыйль кулланылалар, сүз ясалышында катнашалар, төрләнәләр, синтаксик функция башкаралар;

в) реаль мәгънә белдерәләр, яңа сүз ясау өчен нигез булалар, төрләнмиләр, җөмлә кисәге булалар.

18. *Кеше үзенең туган телен кагыйдәсез дә белер һәм һич тә ялгыш әйтмәс һәм хата ясамас* (К. Насыйри) җөмләсендә мөстәкыйль һәм мөстәкыйль булмаган сүз төркемнәренә кергән сүзләр мөнәсәбәте дөрес билгеләнгән вариантны күрсәтегез. **(2 балл)**

а) 12,3;
ә) 11,4;
б) 10,5;

в) 9,6.

## II Теоретик бирем.

Телнең үсешен, кулланылышын һәм төзелешен өйрәнә торган фән ... ... дип атала. **(2 балл)**

Конкрет терминнар һәм кыска җөмләләр белән бу фәннең тармаклары һәм аларның өйрәнү объектлары турында 10-11 ел буе туплаган мәгълүматыгыз белән уртаклашыгыз. **(12 балл)**

## III Иҗади бирем.

*Күрше сөеп күршесен,*
*Дусларча сүз катмаса,*
*Юк ачуны бар итеп,*
*Эчтә бүре сакласа,*
*Иң начары шул икән,*
*Тәүбә, тәүбә бу эштән ...*

М. Җәлил

Ә Сезнең өчен күршеләрегез кем? Алар белән мөнәсәбәтләрегез ничек? Сез аларга, алар Сезгә дусларча сөеп сүз ката беләсезме? Шушы темага караган фикерләрегез белән уртаклашып, 14-15 җөмләдән торган текст языгыз. **(10 балл)**